4) мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи заты яисә муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1.1 өлешендә каралган оешмаларның, аларның хезмәткәрләренең гамәлләре (гамәл кылмаулары) белән алар нигезендә риза булмаган дәлилләре. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан гариза бирүченең дәлилләрен раслаучы документлар (булганда) яки аларның күчермәләре бирелергә мөмкин.

5.7. Мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яисә аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.8. Шикаятькә шикаятьтә бәян ителгән хәлләрне раслый торган документларның күчермәләре кушып бирелергә мөмкин. Мондый очракта шикаятьтә аңа теркәлә торган документлар исемлеге китерелә.

5.9. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча муниципаль хезмәт күрсәтүче орган түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны кире кагу, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән опечатка һәм хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары, Зәй муниципаль районы хокукый актлары белән каралмаган акчаларны кире кайтару рәвешендә дә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язма рәвештә һәм мөрәҗәгать итүченең теләге буенча электрон формада шикаятьне карау нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

5.10. Шикаять канәгатьләндерелергә тиешле дип танылган очракта гариза язучыга җибәрелә торган җавапта, муниципаль хезмәт күрсәткәндә

киткән җитешсезлекләрне тиз арада төзәтү максатыннан, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган, күпфункцияле үзәк яки 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешма тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук килеп туган уңайсызлыклар өчен гафу үтенеп, мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәтне алу максатларында алга таба башкарырга кирәк булган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә.

5.12. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта гариза язучыга җибәрелә торган җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.13. Шикаятьне карау барышында яисә карап тикшерү нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу составы билгеләре яки вазыйфаи затның җинаять эше билгеләре ачыкланганда, шикаятьне карау вәкаләтләре бирелгән хезмәткәр булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына юллый.

Административ регламентка
1 кушымта

# Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф оешмалары турында белешмәләр

| Оешманың исеме | Җитәкченең фамилиясе, исеме, атасының исеме | Оешманың адресы/ сайты | Телефон | Оешманың эш режимы, җитәкченең кабул итү сәгатьләре |
|---|---|---|---|---|
| «Гомумүстерү төрендәге «Аленка» балалар бакчасы» МБМБУ | Храмова Татьяна Валентиновна | 423520 ТР, Зәй ш., Баныкин ур., 9 й. zainskdou9@mail.ru | (885558) 71614 | 6.00 до 18.00 15.00 до 16.30 дүш.- җомга |
| «Гомумүстерү төрендәге «Алтынчәч» балалар бакчасы» МБМБУ | Ишмиева Ангелина Павловна | 423520 ТР, Зәй ш., Ленин ур., 34 «а» й. Leila_must@mail.ru | (885558) 75661 | 6.00 - 18.00 15.00 - 16.30 дүш.- җомга |
| «Каенкай» балалар бакчасы» МБМБУ | Степанова Венера Фаил кызы | 423520 ТР, Зәй ш., Клуб ур., 6 й. zainskdou14@mail.ru | (885558) 66190 | 6.00 - 18.00 15.00 - 16.30 дүш.- җомга |
| «Гомумүстерү төрендәге «Күкчәчәк» балалар бакчасы» МБМБУ | Иванова Светлана Николаевна | 423520 ТР, Зәй ш., Никифоров ур., 77 й. zainskdou12@mail.ru | (885558) 75484 | 6.00 - 18.00 15.00 - 16.30 дүш.- җомга |
| «Гомумүстерү төрендәге «Уймак кыз» балалар бакчасы» МБМБУ | Романова Анна Анатольевна | 423520 ТР, Зәй ш., Ленин ур., 18 «а» й. dyim1957@mail.ru | (885558) 75073 | 6.00 - 18.00 15.00 - 16.30 дүш.- җомга |
| «Бөртеккәй» балалар бакчасы» МБМБУ | Кузнецова Нина Николаевна | 423520 ТР, Зәй ш., Завод ур., 17«б» й. zainskdou6@mail.ru | (885558) 77414 | 6.00 - 18.00 15.00 - 16.30 дүш.-җомга |
| «Гомумүстерү төрендәге «Кыңгырау чәчәк» балалар бакчасы» МБМБУ | Вдовина Людмила Николаевна | 423520 ТР, Зәй ш., Чапаевур., 6 й. zainskdou7@mail.ru | (885558) 72386 | 6.00 - 18.00 15.00 - 16.30 дүш.- җомга |
| «Гомумүстерү төрендәге «Кызыл калфак» балалар бакчасы» МББМУ | Гришина Ирина Ивановна | 423520 ТР, Зәй ш., Рафиков ур., 4 «а» й. zainskdou@mail.ru | (885558) 31225 | 6.00 - 18.00 15.00 - 16.30 дүш.- җомга |
| «Гомумүстерү төрендәге «Урман әкияте» балалар бакчасы» МБМБУ | Габбасова Роза Сөббух кызы | 423520 ТР, Зәй ш., Җиңү пр., 1/01 й. zainskdou13@mail.ru | (885558) 33306 | 6.00 - 18.00 15.00 - 16.30 дүш.- җомга |
| «Компенсацияләүче төрдәге «Тату гаилә» балалар бакчасы» МББМУ | Петрякова Мария Юрьевна | 423520 ТР, Зәй ш., Ленин ур., 3 й. ZaiDrsem@mail.ru | (885558) 72637 | 6.00 - 18.00 15.00 - 16.30 дүш.-җомга |
| «Катнаш төрдәге Салават күпере» балалар бакчасы» МБМБУ | Отакулова Эльвира Мөнир кызы | 423520 ТР, Зәй ш., Җиңү пр., 14 «а» й. douraduga15@mail.ru | (885558) 33305 | 6.00 - 18.00 15.00 16.30 дүш.- җомга |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «Гомумүстерү төрендәге «Миләшкәй» балалар бакчасы» МБМБУ | Каштанова Елена Витальевна | 423520 ТР, Зәй ш., Пионер ур., 14 «б» й. vip.sabarova@mail.ru | (885558) 36115 | 6.00 - 18.00 15.00 - 16.30 дүш.- җомга |
| «Гомумүстерү төрендәге «Якты коңгыз» балалар бакчасы» МБМБУ | Гончарова Алина Фаяз кызы | 423520 ТР, Зәй ш., Энергетиклар ур., д. 13 «а» й. svetlyachok.zainsk@yandex.ru | (885558) 70959 | 6.00 - 18.00 15.00 - 16.30 дүш.- җомга |
| «Гомумүстерү төрендәге «Кояшкай» балалар бакчасы» МБМБУ | Исакова Альфира Габделбәр кызы | 423520 ТР, Зәй ш., Комсомол ур., 65 «а» й. zainskdou5@mail.ru | (885558) 70741 | 6.00 - 18.00 15.00 - 16.30 дүш.- җомга |
| «Гомумүстерү төрендәге «Теремкәй» балалар бакчасы» МБМБУ | Хөснетдинова Венера Ринат кызы | 423520 ТР, Зәй ш., Ленин ур., 6 «а» й. dou-teremok2013@yandex.ru | (885558) 70103 | 6.00 - 18.00 15.00 - 16.30 дүш.- җомга |
| «Катнаш төрдәге «Энже» балалар бакчасы» МББМУ | Мурзагова Венера Равил кызы | 423520 ТР, Зәй ш., Җиңү пр., 14 «б» й. zai.Enzhe@tatar.ru | (885558) 32698 | 6.00 - 18.00 15.00 - 16.30 дүш.- җомга |
| «Гомумүстерү төрендәге «Шатлык» балалар бакчасы» МБМБУ | Борһанова Рәзинә Хафиз кызы | 423520 ТР, Зәй ш., Жуков ур., 9 «а» й. shatlyk.zainsk@mail.ru | (885558) 28024 | 6.00 - 18.00 15.00 - 16.30 дүш.- җомга |
| «Гомумүстерү төрендәге «Тылсымлы әкият» балалар бакчасы» МБМБУ | Тимофеева Татьяна Геннадиевна | 423520 ТР, Зәй ш., Җиңү пр. 34 «а» й. zai.Volshebnaya@yandex.ru | (85558) 2-80-03 | 6.00 - 18.00 15.00 - 16.30 дүш.- җомга |
| «Күбәләк» Бигеш балалар бакчасы» МБМБУ | Зыятдинова Алсу Мәсгуть кызы | 423511 РТ, Зәй р-ны, Бигеш ав., Гагарин ур., 117«а» й. doubegish@mail.ru | (885558) 38038 | 7.00 - 16.00 15.00 - 16.00 дүш.- җомга |
| «Урман көе» Бохарай балалар бакчасы» МБМБУ | Миңлегулова Ләйлә Вәкил кызы | 423536 РТ, Зәй р-ны, Бохарай ав., Новая ур., 4 й. alsu.melodia@mail.ru | (885558) 40435 | 7.00 - 16.00 15.00 - 16.00 дүш.- җомга |
| «Родничок» Гулькин балалар бакчасы» МБМБУ | Григорьева Людмила Дмитриевна | 423507 РТ, Зәй р-ны, Гулькин ав., Үзәк ур., 23 й. gulkinods@mail.ru | (885558) 60807 | 7.00 - 16.00 15.00 - 16.00 дүш.- җомга |
| "Кояшкай" Кадер балалар бакчасы" МБМБУ | Исламова Рәйсә Сөләйман кызы | 423513 РТ, Зәй р-ны, Кадер ав., Яшьләр ур., 3 й. doukader@mail.ru | (885558) 63370 | 7.00 - 16.00 15.00 - 16.00 дүш.- җомга |
| «Ромашка» Сәвәләй балалар бакчасы» МБМБУ | Москова Елена Георгиевна | 423737 РТ, Зәй р-ны, Сәвәләй ав., Яшьләр ур.. 1 й. dou.savaleevo@mail.ru | (885558) 62335 | 7.00 - 16.00 15.00 - 16.00 дүш.- җомга |
| «Аксар төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ | Хәсәншин Рафаил Мөнәвир улы | 423501, РТ, Зәй районы, Аксар ав., Мәктәп ур., 4 й. aksar37@mail.ru | 8(85558) 3-73-34 | 7.00 -16.00 15.00-16.00 дүш.- җомга |
| «Александр Бистәсе төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ | Чуприкова Эльза Таһир кызы | 423503, ТР, Зәй р-ны, Александр Бистәсе ав.,Үзәк урам, 72б й. alslobod77@mail.ru | 8(85558) 6-27-42 | 7.00-16.00 15.00-16.00 дүш.- җомга |
| «Югары Шепкә төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ | Закирова Венера Сәет кызы | 423518, ТР, Зәй р-ны, Югары Шепкә ав., Үзәк урам, 83 й. shipki21@mail.ru | 8(85558) 6-92-66 | 7.00 -16.00 15.00–16.00 дүш.- җомга |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| “Түбән Биш гомуми белем бирү мәктәбе” МБМУ | Иванов Сергей Владимирович | 423514, ТР, Зәй р-ны, Түбән Биш ав., Пролетар ур., 19 й. kaban603@mail.ru | 8(85558) 6-84-10 | 7.00-16.00 15.00-16.00 дүш.- җомга |
| «Поручик төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ | Хәсәншин Ринат Рәис улы | 423520, ТР, Зәй районы, Поручик ав., Чапаев ур., 25 й. sch_poruch@mail.ru | 8(85558) 3-70-96 | 7.00-16.00 15.00-16.00 дүш.- җомга |
| “Чыбыклы төп гомуми белем бирү мәктәбе” МБМУ | Мөхәммәтҗанова Җәмилә Фатих кызы | 423534, ТР, Зәй районы, Чыбыклы ав., Яшьләр ур., 229б й. chubuk3682@mail.ru | 8(85558) 3-68-57 | 7.00-16.00 15.00-16.00 дүш.- җомга |
| “Югары Налим төп гомуми белем бирү мәктәбе” МБМУ | Насыйров Илназ Илсур улы | 423533, ТР, Зәй р-ны, Югары Налим, Яшьләр ур., 1 й. vnalim36@mail.ru | 8(85558) 3-86-31 | 7.00-16.00 15.00-16.00 дүш.- җомга |
| “Якты Күл төп гомуми белем бирү мәктәбе” МБМУ | Кириллова Лидия Яковлевна | 423538, ТР, Зәй районы, Якты Күл ав., Ленин ур., 81 й. svetl68@mail.ru | 8(85558) 6-82-79 | 7.00- 16.00 15.00-16.00 дүш.- җомга |
| "Сарсаз-Баграж төп гомуми белем бирү мәктәбе" МБМУ | Мартемьянов Валентин Иванович | 423516, ТР, Зәй р-ны, Сарсаз-Баграж ав., Мәктәп ур., 4 й. sbag64@mail.ru | 8(85558) 6-44-27 | 7.00-16.00 15.00-16.00 дүш.- җомга |

Административ регламентка
2 кушымта

Шәхси мәгълүматларны автоматлаштырылган эшкәртүгә
РИЗАЛЫК

ГАРИЗА

Мин,______________________________________________________________,
*(Ф.И.О.)*
________________________________________________________________,
*прописка буенча (теркәлү) адрес*
________________________________________________________________,
*(шәхесне раслаучы документ төре, сериясе, номеры, кем тарафыннан бирелгән һәм бирелү датасы)*

Татарстан Республикасының мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына укырга керүче һәм чиратта торучы балаларның мәгълүматлар базасын формалаштыру максатыннан, шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык бирәм:
________________________________________________________________,
*(Ф.И.О., ата-ананың берсенең (законлы вәкилнең) паспорты мәгълүматлары)*
________________________________________________________________,
*(Ф.И.О., туу датасы, баланың туу турында таныклыгы мәгълүматлары)*
________________________________________________________________,
*(факттагы яшәү адресы, баланың сәламәтлеге турында белешмәләр)*
________________________________________________________________,
*(мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенә ташламалы кучерүгә хокуклар булу)*

кәгазь һәм электрон формаларда автоматлаштырылган һәм автоматлаштырылмаган ысул белән шәхси мәгълүматларны җыюны гамәлгә ашыру, системалаштыру, туплау, саклау, төгәлләштерү (яңарту, үзгәртү), файдалану, тарату (шул исәптән тапшыру), зарарсызландыру, блоклау, юк итү.

Әлеге ризалыкның гамәлдә булу вакыты______________________________

Әлеге ризалык минем тарафтан язма рәвештә кире алынырга мөмкин. Әлеге ризалык кире алынган очракта, аның гамәлдә булу вакыты чыкканчы, мин шәхси мәгълүматларны эшкәртүне туктатуның мөмкин булган нәтиҗәләре турында кисәтелгән.

Дата ________________

Гариза бирүченең имзасы__________(______________)*(имзаның расшифровкасы)*

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында «Мәктәпкәчә белем бирү буенча төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына (балалар бакчаларына) балаларны исәпкә кую һәм кабул итү” муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында”**

Балаларга мәктәпкәчә белем бирүне оештыруны камилләштерү максатларында, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү буенча төп гомуми белем бирү программасын (балалар бакчалары) гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм кабул итү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын расларга.

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

“Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү буенча төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына (балалар бакчаларына) балаларны исәпкә кую һәм аларны кабул итү" муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" 2015 елның 20 маендагы 1146 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы башкарма комитеты карарын;

“Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү буенча төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына (балалар бакчаларына) балаларны исәпкә кую һәм

аларны кабул итү" муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" 2015 елның 20 маендагы 1146 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 26 октябрендәге 1848 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы башкарма комитеты карарын;

“Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү буенча төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына (балалар бакчаларына) балаларны исәпкә кую һәм аларны кабул итү" муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" 2015 елның 20 маендагы 1146 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында” 2016 елның 20 июнендәге 1276 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы башкарма комитеты карарын;

“Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү буенча төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына (балалар бакчаларына) балаларны исәпкә кую һәм аларны кабул итү" муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" 2015 елның 20 маендагы 1146 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында” 2018 елның 06 июлендәге 1848 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы башкарма комитеты карарын;

“Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү буенча төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына (балалар бакчаларына) балаларны исәпкә кую һәм аларны кабул итү" муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" 2015 елның 20 маендагы 1146 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында” 2018 елның 04 декабрендәге 1774 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы башкарма комитеты карарын.

3. Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

5.Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.В. Чапковка йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И.Ф. Хафизов**

Л.Р. Печина
3-27-42

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Башкарма комитетының
___ _______2020ел № __
карарына кушымта

“Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү буенча төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына (балалар бакчаларына) балаларны исәпкә кую һәм аларны кабул итү” муниципаль хезмәт күрсәтүнең
АДМИНИСТРАТИВ РЕГЛАМЕНТЫ

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында “мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына (балалар бакчаларына) балаларны исәпкә кую һәм кабул итү” муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (алга таба – административ регламент) муниципаль районда мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына (балалар бакчаларына) мәктәпкәчә яшьтәге балаларны исәпкә кую һәм аларны кабул итү тәртибен билгели.

1.2. Муниципаль хезмәт алучылар булып Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы территориясендә яшәүче 2 айдан 7 яшькә кадәрге балаларның ата-аналары (башка законлы вәкилләре) - Россия Федерациясе, чит ил гражданнары тора.

Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына чираттан тыш урнаштыруга хокуклы (алга таба - оешма):

- судьяларның балалары;
- прокурорларның һәм Россия Федерациясе тикшерү комитеты хезмәткәрләренең балалары;
- Чернобыль АЭСындагы һәлакәт сәбәпле радиация йогынтысына дучар булган гражданнарның һәм аларга тиңләштерелгән категория гражданнарның балалары;
- Россия Федерациясе Эчке эшләр органнары, җинаять-башкарма системасы учреждениеләре һәм органнары, янгынга каршы дәүләт хезмәте хезмәткәрләренең балалары, Россия Федерациясе Милли гвардиясе гаскәрләрендә хезмәт итүче һәм махсус полиция исемнәре булган затлар, Россия Федерациясенең Төньяк Кавказ регионы территориясендә хокук тәртибен һәм җәмәгать куркынычсызлыгын тәэмин итүче контртеррористик операцияләрдә катнашучыларның, террорчылык оешмалары һәм төркемнәре эшчәнлеген туктату, аларның лидерларын һәм затларын ачыклау буенча махсус көчләр составына керүче полиция хезмәткәрләре һәм хезмәткәрләрнең, шулай ук Россия Федерациясенең Төньяк Кавказ төбәге территориясендә террорчылыкка каршы операцияләр уздыру буенча

гаскәрләрнең (көчләрнең) Берләштерелгән төркеме хезмәткәрләре һәм хәрби хезмәткәрләренең балалары.

Оешмага беренче чиратта урнаштыру хокукына ия:
- инвалид балалар һәм әти-әниләре инвалид булган балалар;
- күп балалы гаилә балалары;
- полиция хезмәткәре балалары, шул исәптән, хезмәт вазыйфаларын үтәү белән бәйле рәвештә сәламәтлегенә зыян килү яки башка төрле зыян нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) полиция хезмәткәренең балалары; полициядә хезмәт иткәндә алынган авыру нәтиҗәсендә вафат булган полиция хезмәткәренең балалары; хезмәт бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә алынган гариплек яисә сәламәтлеккә башка төрле зыян килү нәтиҗәсендә полициядә хезмәттән азат ителгән Россия Федерациясе гражданины балалары; хезмәт бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә алынган гариплек яисә сәламәтлеккә башка төрле зыян килү нәтиҗәсендә полициядә хезмәттән азат ителгәннән соң бер ел эчендә вафат булган яисә полициядә хезмәт узу чорында алынган, алга таба полициядә хезмәт итү мөмкинлеген калдырмаган авыру нәтиҗәсендә эштән китәргә мәҗбүр булган Россия Федерациясе гражданы балалары; Россия Федерациясе гражданины, полиция хезмәткәре иждивениесендәге балалар;
- хәрби хезмәткәрләрнең балалары;
- махсус исемнәргә ия булган һәм җинаять-башкарма системасы учреждениеләрендә һәм органнарында, янгынга каршы федераль хезмәт һәм Россия Федерациясе таможня органнарында хезмәт итүче хезмәткәрләрнең балалары, җинаять-башкарма системасы учреждениеләрендә һәм органнарында, дәүләт янгынга каршы хезмәтенең федераль янгынга каршы хезмәтендә, Россия Федерациясе таможня органнарында хезмәттән азат ителгән хезмәткәрләр, Россия Федерациясе гражданнарының балалары.

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы территориясендә үз исәбенә өстәмә мәктәпкәчә урыннар булдырган оешма хезмәткәрләренең балалары гамәлдәге законнар нигезендә Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы катнашында төзелә торган дәүләти-хосусый партнерлык турында килешү шартларында каралган санда мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында урыннар белән тәэмин ителә.

Оешмага өстенлекле шартларда урнашу хокукына бертуганнары, абыйлары һәм (яисә) апалары укый торган, бер гаиләдә яшәүче һәм гомуми яшәү урыны бер булган балалар ия.

Игезәк балаларның берсе оешмага урнаштырылган очракта, аларның икенчесе (һәм аннан соңгысы) әлеге оешмага чираттан тыш тәртиптә кабул ителә.

Федераль законнар, Татарстан Республикасы законнарында һәм законга караган норматив-хокукый актларда каралмаган башка нигезләр буенча ташламалар бирү рөхсәт ителми.

1.3. Муниципаль хезмәт «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ һәм әлеге административ регламентка 1 кушымтада күрсәтелгән мәгариф учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә.

1.4. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенең урнашкан урыны: Зәй ш., Крупская ур., 6 й.

«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенең эш графигы: сишәмбе – 8.00 - 12.00, чәршәмбе – 13.00 - 16.00.

1.5. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенең белешмәләр өчен телефоннары: 8 (85558) 3-16-77, 7-08-13.

1.6. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенең интернет челтәрендә рәсми сайты адресы: zai.roo@mail.ru.

1.7. Оешмаларның рәсми сайтларының адреслары, урнашу урыны, эш графигы, белешмә телефоннары турында мәгълүмат 1 кушымтада күрсәтелгән.

1.8. Муниципаль хезмәт турында мәгълүматны алырга мөмкин:

- мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү өчен бүлмәләрдә урнашкан муниципаль хезмәт турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмат стендларыннан. Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә мәгълүмат әлеге административ регламентның 1.1, 1.3, 2.3, 2.5, 2.9, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларындагы) муниципаль хезмәт турында белешмәләрне үз эченә ала;

- «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенең рәсми сайтыннан;

- Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында бирелгән https://uslugi.tatar.ru/cei/fedback кире элемтә формасы аша һәм 8(843)5-114-115 техник ярдәм хезмәте телефоны буенча;

- «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенә телдән мөрәҗәгать иткәндә;

- «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенә язмача мөрәҗәгать иткәндә.

1.9. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге норматив хокукый актлар нигезендә гамәлгә ашырыла:

Россия Федерациясе Конституциясе ("Российская газета", N 7, 21.01.2009);

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон ("Российская газета", N 303, 31.12.2012.);

«Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» 1998 елның 24 июлендәге 124-ФЗ номерлы Федераль закон ("Российская газета", N 147, 05.08.1998);

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон ("Российская газета", N 202, 08.10.2003);

«Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 02 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон ("Российская газета", N 95, 05.05.2006);

«Электрон рәвештә күрсәтелә торган беренче чираттагы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең җыелма исемлеген раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 17 декабрендәге 1993-р номерлы күрсәтмәсе ("Российская газета", N 247, 23.12.2009);

“Дәүләт яисә муниципаль хезмәтләр реестрына кертелергә тиешле һәм электрон рәвештә күрсәтелә торган дәүләт йөкләмәсе (заказ) яисә муниципаль йөкләмә (заказ) урнаштырылган дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр һәм башка оешмалар күрсәтә торган хезмәтләр исемлеген раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 25 апрелендәге 729-р номерлы күрсәтмәсе ("Российская газета", N 93, 29.04.2011);

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июнендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон ("Российская газета", N 168, 30.07.2010) (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон);

«Инвалидларга дәүләт ярдәменең өстәмә чаралары турында» Россия Федерациясе Президентының 1992 елның 02 октябрендәге 1157 номерлы Указы ("Собрание актов Президента и Правительства РФ", 05.10.1992, N 14, ст. 1098);

«Күп балалы гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтү чаралары турында» 05.05.1992 елның 05 маендагы 431 номерлы РФ Президенты Указы ("Ведомости СНД и ВС РФ", 14.05.1992, N 19, ст. 1044);

«Полиция турында» 07.02.2011 елның 07 февралендәге 3-ФЗ номерлы Федераль закон ("Российская газета", N 25, 08.02.2011);

"Хәрби хезмәткәрләрнең статусы турында" 1998 елның 27 маендагы 76-ФЗ номерлы Федераль законы ("Российская газета", N 104, 02.06.1998);

Россия Федерациясе Прокуратурасы турында 1992 елның 17 гыйнварындагы 2202-1 номерлы Закон ("Российская газета", N 39, 18.02.1992);

«Россия Федерациясендә судьялар статусы турында» 1992 елның 26 июнендәге 3132-1 номерлы Россия Федерациясе Законы ("Российская газета", N 170, 29.07.1992);

«Чернобыль АЭС һәлакәте нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган гражданнарны социаль яклау турында» 1991 елның 15 маендагы 1244-1 номерлы Россия Федерациясе Законы ("Ведомости СНД и ВС РСФСР", 1991, N 21, ст. 699);

«Татарстан Республикасында дәүләти-хосусый партнерлык турында» 2011 елның 1 августындагы 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы («Республика Татарстан», № 156, 05.08.2011 г.);

«Янгын куркынычсызлыгы турында» 21.12.1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль закон («Российская газета», №3, 05.01.1995 г.);

"Кайбер федераль башкарма хакимият органнары хезмәткәрләренең социаль гарантияләре һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2012 елның 30 декабрендәге 283-ФЗ номерлы Федераль закон ("Российская газета", № 3, 11.01.2013);

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законга мөрәҗәгать итүче тарафыннан бердәм гариза бирү юлы

белән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә берничә дәүләт (муниципаль) хезмәт күрсәтү мөмкинлеген беркетү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында" 2017 елның 29 декабрендәге 479-ФЗ номерлы Федераль закон;

"Россия Федерациясенең Төньяк Кавказ регионы территориясендә хокук тәртибен һәм җәмәгать куркынычсызлыгын тәэмин итүче контртеррорчылык операцияләрендә катнашучы федераль башкарма хакимият органнары хәрбиләренә һәм хезмәткәрләренә өстәмә гарантияләр һәм компенсацияләр турында" 2004 елның 09 февралендәге 65 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары («Российская газета», №28, 13.02.2004 г.);

"Дагыстан Республикасы территориясендә террорчылыкка каршы көрәштә турыдан-туры катнашкан һәм һәлак булган (хәбәрсез югалган), вафат булган, хезмәт бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә инвалид булган хәрби хезмәткәрләрнең һәм эчке эшләр органнары, дәүләт янгынга каршы хезмәте, җинаять-башкарма системасы хезмәткәрләренең гаиләләрен социаль яклау буенча өстәмә чаралар турында" 1999 елның 25 августындагы 936 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары («Российская газета», №169, 31.08.1999 г.);

"Төп гомуми белем бирү программалары - мәктәпкәчә белем бирүнең мәгариф программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында" 2013 елның 30 августындагы 1014 номерлы Россия Федерациясе мәгариф һәм фән министрлыгы приказы ("Российская газета", N 238, 23.10.2013);

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы уставы.

## II. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

| Стандартка таләпнең аталышы | Стандартка таләпләрнең эчтәлеге | Муниципаль хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгеле торган норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1.Муниципаль хезмәтнең атамасы | Мәктәпкәчә белем бирү буенча төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына (балалар бакчаларына) балаларны исәпкә кую һәм кабул итү. | Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының "Төп гомуми белем бирү программалары - мәктәпкәчә белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында" 2013 елның 30 августындагы 1014 номерлы боерыгы |
| 2.2.Башкарма хакимият органының исеме | Муниципаль хезмәт «Башкарма комитетның мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе һәм әлеге административ регламентның 1 кушымтасында күрсәтелгән мәктәпкәчә белем бирү оешмалары тарафыннан күрсәтелә. | «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон |

| | | |
|---|---|---|
| | Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затлар булып «ТР ЗМР башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ (алга таба - вәкаләтле хезмәткәр) хезмәткәрләре тора.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтүче органнар мөрәҗәгать итүчедән, әлеге административ регламентта каралган мондый хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәсендә күрсәтелә торган документлар һәм мәгълүмат алудан тыш, муниципаль хезмәт алу өчен кирәкле һәм башка дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына, оешмаларга мөрәҗәгать итү белән бәйле гамәлләрне, шул исәптән муниципаль хезмәт алу өчен кирәкле килештерүләрне, гамәлгә ашыруны таләп итәргә хокуклы түгел. | |
| 2.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама | Муниципаль хезмәт күрсәтүнең нәтиҗәсе булып баланы мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын тормышка ашыручы мәгариф оешмасына (балалар бакчасы) баланы кабул итү тора. | "Төп гомуми белем бирү программалары - мәктәпкәчә белем бирүнең мәгариф программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында" 2013 елның 30 августындагы 1014 номерлы Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы приказы |
| 2.4.Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып | Исәпкә кую өлешендә муниципаль хезмәт күрсәтү Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (uslugi.tatarstan.ru), дәүләт хезмәтләренең бердәм порталында (gosuslugi.ru) гариза тутыру яисә кәгазь чыганакта мәгариф идарәсенә гариза бирү мизгеленнән гамәлгә ашырыла.<br>Оешмага балаларны кабул итү өлешендә муниципаль хезмәт күрсәтү "Шартнамә төзү" статусы бирелгәннән соң, буш урыннар булганда һәм агымдагы елның 31 августыннан да соңга калмыйча, төп комплектлау чорында 30 календарь көннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла. | "Төп гомуми белем бирү программалары - мәктәпкәчә белем бирүнең мәгариф программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында" 2013 елның 30 августындагы 1014 номерлы Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы приказы |
| 2.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен законнар һәм башка норматив | 1. Гариза бирүче баланы исәпкә кую өчен гариза тапшырганда кирәкле белешмәләр исемлеге:<br>- баланың фамилиясе, исеме, атасының | |

| | | |
|---|---|---|
| хокукый актлар, шулай ук<br>мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр, аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе<br>нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге | исеме;<br>- баланың туу датасы;<br>-туу турында таныклык мәгълүматлары;<br>- фактта яшәү урыны (адресы);<br>- әнисе, әтисе яисә законлы вәкилләрнең фамилиясе, исеме, атасының исеме, электрон почта адресы, телефон номеры;<br>- ата-ананың (законлы вәкилнең) шәхесен раслаучы документ белешмәләре;<br>- баланы мәгариф оешмасына урнаштыруда ташламалар булу турында белешмәләр;<br>- баланың сәламәтлеге буенча ихтыяҗы;<br>- бер теләгән оешма;<br>- төркемдә теләгән тәрбия һәм укыту теле;<br>- баланы оешмага урнаштыруның теләгән датасы;<br>- теләгән оешмада урын булмаганда башка балалар бакчасы тәкъдименә ризалык/риза булмау.<br>2. Баланы оешмага урнаштыру өчен кирәкле документлар исемлеге (гариза бирүче тарафыннан оешмага шәхсән мөрәҗәгать иткәндә бирелә):<br>- оешма җитәкчесе исеменә ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) язмача гаризасы;<br>- билгеләнгән үрнәктәге медицина бәяләмәсе (сәламәтлек саклау учреждениеләре тарафыннан бирелә);<br>- баланың ата-анасының (законлы вәкилләренең) берсенең шәхесен раслаучы документ;<br>- психологик-медик-педагогик комиссия бәяләмәсе (баланы компенсацияләүче һәм катнаш юнәлештәге төркемнәргә керткәндә таләп ителә, психологик-медик-педагогик комиссия тарафыннан бирелә) | |
| 2.6. Оешмага кабул итү өчен кирәкле документлар исемлеге | - оешма җитәкчесе исеменә әти-әниләрнең (законлы вәкилләрнең) язмача гаризасы;<br>- билгеләнгән үрнәктәге медицина бәяләмәсе;<br>- баланың ата-анасының (законлы вәкилләренең) берсенең шәхесен таныклаучы документ;<br>- психологик-медик-педагогик | "Төп гомуми белем бирү программалары - мәктәпкәчә белем бирүнең мәгариф программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында" 2013 елның 30 августындагы |

| | | |
|---|---|---|
| | комиссия бәяләмәсе (баланы компенсацияләүче һәм катнаш юнәлештәге төркемнәргә керткәндә таләп ителә, психологик-медик-педагогик комиссия тарафыннан бирелә) | 1014 номерлы Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы приказы |
| 2.7. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | исәпкә алу өлешендә:<br>- оешмага кабул ителә торган балаларның максималь яшен арттыру; | «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон |
| 2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору яки аны күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | 1) исәпкә алу өлешендә:<br>- баланың туу турында таныклык мәгълүматларын идентификацияләү процедурасына комачаулаучы дөрес булмаган (җитәрлек булмаган) мәгълүматларны бирү;<br>- оешмага кабул ителә торган балаларның максималь яшен арттыру;<br>2) балаларны кабул итү өлешендә:<br>- белем бирү оешмасына кабул итүдән бары тик анда буш урыннар булмау сәбәпле генә баш тартырга мөмкин. | «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон<br>"Төп гомуми белем бирү программалары - мәктәпкәчә белем бирүнең мәгариф программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында" 2013 елның 30 августындагы 1014 номерлы Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы приказы |
| 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен алына торган дәүләт пошлинасын яисә башка түләүне алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Муниципаль хезмәт түләүсез нигездә күрсәтелә. | «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон |
| 2.10. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмалар тарафыннан бирелә торган документ(документлар) турында белешмәләр | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми. | |
| 2.11. Муниципаль хезмәт күрсәтү, муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы | Шәхси кабул итүне көтеп тору вакыты 15 минуттан да артмаска тиеш. Әгәр хезмәт пенсионерларга, инвалидларга | |

| | | |
|---|---|---|
| оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрне күрсәтү турындагы гарызнамә биргәндә һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратның максималь вакыты | күрсәтелә икән, киләсе мөрәҗәгать итүченең көтү (хезмәт күрсәтү) вакыты 30 минутка кадәр озайтылырга мөмкин.<br>Барлык мөрәҗәгать иткән затларны кабул итү эш көне тәмамланырга 1 сәгатьтән дә соңга калмыйча башкарылырга тиеш. | |
| 2.12.Муниципаль хезмәт күрсәтү турында, шул исәптән электрон формада, гариза бирүченең үтенечен теркәү срогы | “Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» муниципаль бюджет учреждениесенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә исәпкә кую турында гаризаны теркәү административ регламентның III бүлегендә каралган тәртиптә мөрәҗәгать иткән мизгелдән 1 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.<br>Баланы оешмага алу турында гаризаны теркәү әлеге административ регламентның III бүлегендә каралган тәртиптә мөрәҗәгать иткән вакыттан 1 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла. | |
| 2.13. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр | Мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү өчен биналарда муниципаль хезмәт турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган муниципаль хезмәт турында мәгълүмат стендлары урнаштырыла. Бинаның алгы өлешенә мәгариф идарәсенең муниципаль органы исеме турында мәгълүмат урнаштырыла.<br>Кабул итүне көтеп тору, документларны рәсмиләштерү өчен мөрәҗәгать итүчеләргә урындыклар, өстәлләр белән җиһазландырылган урыннар бирелә.<br>Бина санитария кагыйдәләре һәм нормалары нигезендә җиһазландырылырга тиеш. | “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 2010 елның 27 июнендәге 210-ФЗ Федераль закон |
| 2.14.Муниципаль хезмәт күрсәтүдән файдалану мөмкинлеге һәм сыйфат күрсәткечләре | - документларны кабул итү һәм карау срокларын үтәү;<br>- муниципаль хезмәт нәтиҗәсен алу срогын үтәү;<br>- вазыйфаи затлар тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы булган муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын бозуга прецедентлар (нигезле шикаятьләр) булмау. | “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 2010 елның 27 июнендәге 210-ФЗ Федераль закон |

| | | |
|---|---|---|
| | | |
| 2.15. Электрон формада муниципаль хезмәт күрсәтү үзенчәлекләре | Электрон рәвештә хезмәт күрсәтү Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (https://uslugi.tatar.ru) аша гамәлгә ашырыла. | “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыр турында" 2010 елның 27 июнендәге 210-ФЗ Федераль закон |
| 2.16. Җирле үзидарә дәүләт органнары һәм башка оешмалар карамагында булган һәм мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге | Ташламаларны раслый торган документлар:<br>- күпбалалы гаиләләр балалары;<br>- Чернобыль АЭСындагы һәлакәт нәтиҗәсендә радиациягә дучар булган гражданнарның балалары;<br>- инвалид балалар;<br>- ата-аналарның берсе инвалид гаилә балалары.<br>Документлар социаль яклау территориаль органнары тарафыннан бирелә. | "Мәктәпкәчә белем бирү буенча төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм урнаштыру" муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының үрнәк формасын раслау турында» 2015 елның 10 мартындагы 1389/15 номерлы Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы |
| 2.17. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен мөмкин булуын тәэмин итүгә таләпләр | - муниципаль хезмәт күрсәтелә торган объект урнашкан территория буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге, шулай ук бинага керү һәм чыгу, транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү, шул исәптән кресло-коляска кулланып;<br>- күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функциясе бозылган инвалидларны озатып йөрү;<br>- хезмәт күрсәтүче оешма хезмәткәрләре тарафыннан башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә хезмәт алуга комачаулый торган каршылыкларны җиңүдә инвалидларга ярдәм күрсәтү;<br>- хезмәт күрсәтелә торган объектка, тиешле документы булганда, озатып йөрүче эт белән керүне рөхсәт итү<br>- инвалидларның тоткарлыксыз үтүен тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүматны тиешенчә урнаштыру. | "Инвалидлар хокуклары турында конвенцияне ратификацияләүгә бәйле рәвештә инвалидларны социаль яклау мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 2014 елның 1 декабрендәге 419-ФЗ номерлы Федераль закон» |

## III. Административ процедуралар

### Муниципаль хезмәт күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелеге тасвирламасы

3.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

- исәпкә кую («Электрон балалар бакчасы» автоматлаштырылган мәгълүмат системасында (алга таба – система) исәпкә кую өчен гаризаны теркәү);
- оешмага юллама бирү;
- оешмага кабул итү.

3.2. Мөрәҗәгать итүчегә консультацияләр бирү.

Мөрәҗәгать итүче шәхсән, телефон аша, электрон почта аша «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенә муниципаль хезмәт алу тәртибе турында консультацияләр алу өчен мөрәҗәгать итә. Вәкаләтле хезмәткәр мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт алу өчен кирәкле документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча консультация бирә һәм, кирәк булганда, гариза тутыруда ярдәм күрсәтә. Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгате көнендә гамәлгә ашырыла.

3.3. Исәпкә кую.

3.3.1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты каршында ел саен учреждениеләрне комплектлау буенча комиссия төзелә, аның составы Зәй муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан раслана.

Оешмага урнашу буенча исәпкә кую өчен ата-аналар (законлы вәкилләр) гаризаларын тутыру гамәлгә ашырыла:

- Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша (uslugi.tatar.ru);

- дәүләт хезмәтләренең бердәм порталы аша (gosuslugi.ru);

- «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе" муниципаль казна учреждениесенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә.

Гаризалар кабул итү һәм аны теркәү системада ел дәвамында башкарыла.

«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе" муниципаль казна учреждениесенә мөрәҗәгать иткәндә әлеге гаризаларны системага мәгариф идарәсе органы боерыгы белән билгеләнгән вәкаләтле хезмәткәр кертә. Системага мәгълүматларны кертү гариза бирүче мөрәҗәгать иткән мизгелдән 1 эш көне эчендә башкарыла.

Гаризаны тутырганда ата-аналар (законлы вәкилләр) шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык бирә (административ регламентка 2 кушымта).

3.3.2. Исәпкә алу өчен гариза биргәндә, система тарафыннан туу турында таныклыкның дөреслеген тикшерү гамәлгә ашырыла. Әгәр мәгълүматлар дөрес түгел, йә юк икән, системада гаризага "Документларны раслау”

статусы бирелә. Бу очракта гариза бирүчегә документларны раслау өчен «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенең кабул итү сәгатьләренә килергә кирәк. Документларны гариза бирүче раслаганнан соң, вәкаләтле хезмәткәр, документлар расланганнан соң, 1 эш көне эчендә системада гаризага «Теркәлгән» статусын бирә.

3.3.3. Законлы вәкил (опекун, попечитель) гариза биргән очракта, системада гариза «Опеканы (попечительлекне) раслау" статусын ала. Бу очракта гариза бирүчегә опека (попечительлек) турында документларны раслау өчен «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенә килергә кирәк. Документларны гариза бирүче раслаганнан соң, вәкаләтле хезмәткәр, документлар расланганнан соң, 1 эш көне эчендә гаризага «Теркәлгән» статусын бирә.

3.3.4. Әгәр мөрәҗәгать итүче чираттан тыш, беренче чиратта оешмага керү хокукына ия булса, аның гаризасына «Документларны раслау» статусы бирелә. Мөрәҗәгать итүчегә «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенә ташламаны раслый торган документның оригиналын, түбәндәге ташламаларны раслый торган документлардан тыш, шулай ук аның күчермәсен тапшырырга кирәк:

күп балалы гаилә балалары;

Чернобыль АЭСындагы һәлакәт нәтиҗәсендә радиациягә дучар ителгән гражданнарның балалары;

инвалид балалар;

әти-әнинең берсе инвалид булган гаиләләр.

Ташламаларның әлеге исемлеге Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенә Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы белән бирелгән гаризалар буенча шәхси визитын төшереп калдыру өчен Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы халкының социаль регистры» дәүләт мәгълүмат системасына запрос ярдәмендә автомат рәвештә раслана. Ташламаны раслаучы документ күчермәсе «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе " муниципаль казна учреждениесендә саклана.

3.3.5. Гаризаның статусын һәм чираттагы урын турында хәлне Татарстан Республикасының https://uslugi.tatar.ru дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша, бала туу турындагы таныклык (серия һәм номер) яисә

гаризаның индивидуаль идентификация номеры буенча, gosuslugi.ru дәүләт хезмәтләренең бердәм порталы аша, шулай ук «ТР Зәй муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ аша шәхси мөрәҗәгать иткәндә яисә телефон буенча кабул итү сәгатьләрендә тикшерергә мөмкин.

Исәпкә басканда, гариза бирүче гаризада баланы урнаштыру өчен бер оешманы күрсәтергә хокуклы.

Гаризага индивидуаль идентификация номеры бирелгәннән соң, гариза бирүче гаризасы буенча оешманы алыштыру рөхсәт ителә. Мөрәҗәгать итүче теләгән оешмага алмаштыру буенча гаризаны оешманың урнашу урыны буенча мәгариф идарәсенә бирә. Исәпкә кую датасы шул ук саклана.

Шулай ук мөрәҗәгать итүче теләгән оешманы gosuslugi.ru дәүләт хезмәтләренең бердәм порталы аша гариза биреп үзгәртә ала.

Вәкаләтле хезмәткәр, гариза биргән көннән алып, 5 эш көне эчендә, җибәрелгән хаталарны (баланың исем-фамилиясендә, туу датасы, туу турында таныклык реквизитларында һ.б. шундыйлар, исәпкә кую датасыннан тыш) төзәтү максатында, граждан гаризасына тиешле төзәтмәләр кертергә хокуклы. Әлеге вакыт узганнан соң үзгәрешләр кертү система администраторы тарафыннан вәкаләтле хезмәткәр гаризасы буенча гамәлгә ашырыла.

Гариза бирүченең баласына 8 яшь тулса, исәпкә кую турындагы гариза вәкаләтле хезмәткәр тарафыннан «Архив» статусына күчерелә.

Элек исәпкә куелган баланы буш урыннар булган авыл оешмасына исәпкә кую һәм урнаштыру рөхсәт ителә. Гариза авыл оешмасы урнашкан урын буенча мәгариф идарәсе органнарына тапшырыла. Беренчел гариза буенча теләгән оешмага чират саклана.

Яңа оешмалар системага вәкаләтле хезмәткәр гаризасы буенча система администраторы тарафыннан кертелә.

3.3.6. Балаларны комплектлау башлаганчы 30 календарь көн алдан оешма «ТР Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенә раслауга чираттагы уку елында һәр яшь категориясе (планлы төркемнәр) нигезендә төркемнәрдә буш урыннар саны турында белешмәләр тапшыра.

Оешмаларны чираттагы уку елына туплау расланган сандагы төркемнәр һәм алардагы буш урыннар нигезендә чираттагы уку елына агымдагы елның 1 июненнән 31 августына кадәр гамәлгә ашырыла. Комплектацияләгәндә балаларның яше агымдагы елның 1 ноябренә исәпләнә.

Оешмаларда тәрбияләнүчеләр киткән, яңа мәктәпкәчә урыннар тапшырылган очракта, уку елы дәвамында әлеге административ регламентның 3.5 пунктында беркетелгән оешмага юллама һәм исәпләү тәртибенә ярашлы рәвештә, оешмаларны тулыландыру эше башкарыла.

Оешмаларны комплектлаштырып бетерүдә, системада балаларның яшен хисаплауны үзгәртү кирәк булганда, агымдагы елның 1 ноябреннән 31 декабренә кадәр муниципаль берәмлек башкарма комитеты тарафыннан ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы адресына гариза юллана. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән килешенеп, өстәмә комплектлау датасы билгеләнә, бу көнне система администраторы тарафыннан балаларның яшен исәпләүне үзгәртү гамәлгә ашырыла.

Комплектлау нәтиҗәләре турында гражданнарга мәгълүмат "Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе" МКУ мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән җиткерелә.

Оешмаларны комплектлаганда гражданнар гаризасы вәкаләтле хезмәткәрләр тарафыннан 5 эш көненнән дә артык эшкәртелә алмый.

3.4. Оешмага юллама һәм кабул итү.

3.4.1. Гариза бирүченең чираты җиткәндә һәм тиешле яшь төркемендә урын булганда, гаризага теләгән «Оешмага җибәрелде» статусы бирелә. Әлеге статусны бирү турындагы хәбәр Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында, Бердәм дәүләт хезмәтләре порталында чагылдырыла.

3.4.2. Мөрәҗәгать итүче «Оешмага җибәрелде» статусы бирелгәннән соң 30 календарь көнгә кадәр баланы алуны раслау өчен оешмага килергә тиеш.

3.4.3. Оешма җитәкчесе, гариза бирүче баланы алу турындагы гаризасы белән мөрәҗәгать иткәннән соң, 1 эш көне дәвамында системада гаризага «Килешү төзү» статусы бирә.

Агымдагы елның сентябреннән алып май аена кадәр чорда «Килешү төзү» статусы бирелгән көннән алып 1 ай эчендә гариза бирүче килешү төзү өчен оешмага килергә тиеш.

Агымдагы елның июненнән августына кадәр «Килешү төзү» статусы бирелгән көннән алып 3 ай эчендә гариза бирүче килешү төзү өчен оешмага килергә тиеш.

3.4.4. Әгәр мөрәҗәгать итүчене бала җибәрелгән оешма канәгатьләндермәсә, гариза бирүче әлеге оешмага бирелгән юлламадан баш тарта. Гаризага «Теркәлгән» статусы бирелә. Шул ук вакытта исәпкә кую датасы үзгәрми.

Тәкъдим ителгән оешмага юлламадан баш тарту «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ тарафыннан билгеләнгән форма буенча шәхсән мөрәҗәгать иткәндә язмача рәсмиләштерелә.

3.4.5. Гаризага «Оешмага җибәрелде» статусы бирелгәннән соң гариза бирүче тиешле срокта оешмага килмәгән очракта, административ регламентның 3.5.2 пунктында билгеләнгәнчә, гариза бирүчегә муниципаль

хезмәт күрсәтү туктатыла. Оешма җитәкчесе гариза бирүченең системадагы гаризасына “Килмәде” статусы бирә.

3.4.6. Әгәр дә мөрәҗәгать итүче хезмәт алуга үз теләген расласа, гаризага "Теркәлгән" статусы бирелә. Исәпкә кую датасы шул ук вакытта үзгәрми. Мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт алудан баш тартса, гаризага «Хезмәттән баш тартты» статусы бирелә. Муниципаль хезмәт күрсәтүне раслау яисә аны алудан баш тарту «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының мәгариф идарәсе» МКУ билгеләгән рәвештә яшәү урыны буенча мәгариф идарәсе органнарына шәхсән мөрәҗәгать иткәндә язмача рәвештә рәсмиләштерелә.

3.5. Оешмага исәпкә алу

3.5.1. Ата-аналар (законлы вәкилләр) белән килешү төзелгәннән соң, оешма җитәкчесе 1 эш көне дәвамында Системага килешү реквизитларын кертә һәм Системада "Оешмада исәпкә алынды" статусын бирә.

Баланы карау һәм тәрбияләү өчен ата-ана түләве "Оешмада исәпкә алынды" статусын биргән көннән билгеләнә.

3.5.2. Гариза бирүче билгеләнгән вакытта килешү төзү өчен билгеләнгән срокта килмәгән очракта, оешма җитәкчесе гаризага "Килмәде" статусын бирә.

3.5.3. Әгәр гариза бирүче үзенең хезмәт алу теләген раслый икән, гаризага «Теркәлгән» статусы бирелә. Исәпкә кую датасы үзгәрми.

Әгәр мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тартса, гаризага «Хезмәт күрсәтүдән баш тарткан» статусы бирелә. Муниципаль хезмәт күрсәтүне раслау яки баш тарту "Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе" МКУ тарафыннан билгеләнгән формада яшәү урыны буенча мәгариф идарәсе органнарына шәхси мөрәҗәгать иткәндә язмача рәсмиләштерелә.

3.5.4. Компенсацияләүче һәм сәламәтләндерү юнәлешендәге төркемнәргә гаризаларында сәламәтлек буенча ихтыяҗ күрсәтелгән балалар җибәрелә.

Баланы билгеле бер вакытка (вакытлыча, медицина бәяләмәсе яки психологик-медик-педагогик комиссия бәяләмәсе нигезендә) компенсацияләүче яки сәламәтләндерү юнәлешендәге төркемгә җибәргән очракта, юлламада «Вакытлыча урнаштыру» дигән билге куела.

Баланың гаризасы исәпкә куюның беренчел датасы белән чиратта саклана.

Әгәр бала компенсацияләүче яки сәламәтләндерү юнәлешендәге төркемгә җибәрелгән вакытка башка оешмага йөргән булса, оешма җитәкчесе, махсуслаштырылган төркемдә булу вакытын күрсәтеп, баланы вакытлыча исәптән төшереп тора.

3.5.5. Физик мөмкинлекләре чикләнгән балаларны, инвалид балаларны оешманың компенсацияләүче һәм катнаш юнәлештәге төркемнәренә күчерү психологик-медик-педагогик комиссия бәяләмәсе нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.6. Ата-аналар гаризасы буенча баланы бер оешмадан икенчесенә күчерү рөхсәт ителә.

Баланы бер оешмадан икенчесенә күчерү өчен гариза теләгән оешма урнашкан урын буенча мәгариф идарәсе органнарына тапшырыла.

3.6.1. Әлеге гариза системага кертелгәндә ата-аналарга тиешле гаризаны бирү датасы куела. Оешмаларны комплектлаганда баланы бер оешмадан икенчесенә күчерүгә гариза гомуми чират тәртибендә карала.

3.6.2. Гражданнар гаризалары буенча (ихтыяҗ булган ике яктан) төрле оешмаларның бер яшь категориясенә керүче яшьтәш ике баланың урыннарын алмаштыру рөхсәт ителә. Урын алмаштыруга гаризалар «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУга тапшырыла.

3.6.3. Оешма бетерелгәндә яки эшчәнлеге туктатылган очракта, тәрбияләнүчеләр башка оешмаларга чираттан тыш тәртиптә кабул ителә.

3.6.4. Баланы балалар бакчасыннан чыгарган очракта, тиешле боерыкны теркәгән көннән алып 1 эш көне дәвамында оешма җитәкчесе системада гаризага "Чыгарылды" статусын бирә.

## IV. Муниципаль хезмәт күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары.

4.1. Әлеге Административ регламентның үтәлешенә агымдагы контроль «ТР Зәй муниципаль районының мәгариф идарәсе» МКУ җитәкчесе яки аның урынбасары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге мәгариф идарәсе органы приказы белән билгеләнә торган вәкаләтле хезмәткәр законнар нигезендә әлеге административ регламент нигезләмәләрен үтәгән өчен җаваплылык тота.

4.2. Муниципаль хезмәт күрсәтүгә агымдагы контроль вәкаләтле хезмәткәрләр, оешмалар җитәкчеләре тарафыннан әлеге Административ регламент нигезләмәләренең үтәлешен һәм башкарылуын тикшерү юлы белән гамәлгә ашырыла.

4.3. Муниципаль хезмәт күрсәтүгә агымдагы контроль даими нигездә башкарыла.

4.4.Муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгы һәм сыйфатына контроль тикшерүләр үткәрү, мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылуларны ачыклау һәм бетерү, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затларның карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр булган мөрәҗәгать итүчеләрнең мөрәҗәгатенә карата карарлар кабул итү һәм җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

4.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшерүләр «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының мәгариф идарәсе» МКУ актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Тикшерүләр планлы («Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының мәгариф идарәсе» МКУ ярты еллык яисә еллык эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш булырга мөмкин.

4.5. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын планнан тыш тикшерү үткәрү турында карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) муниципаль хезмәт күрсәтүгә таләпләрне билгели торган административ регламент һәм башка норматив хокукый актлар таләпләрен элек бозган очракларны бетерүгә бәйле рәвештә;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затларга карата хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре бозылуга шикаятьләр белән гражданнар мөрәҗәгатьләре буенча.

4.6. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшерү нәтиҗәләре ачыкланган җитешсезлекләр һәм аларны бетерү буенча тәкъдимнәр күрсәтелгән акт белән рәсмиләштерелә.

4.7. Контроль нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылган очракта гаепле затларны җаваплылыкка тарту Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

4.8. Мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүгә контроль әлеге административ регламентта каралган мәгълүматны алу юлы белән, шулай ук вазыйфаи затның муниципаль хезмәт күрсәткәндә кабул итә торган карар гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять бирү юлы белән гамәлгә ашырыла.

4.9. Тикшерү барышында ачыкланган гражданнарның законлы хокуклары һәм мәнфәгатьләре бозылу очраклары, ачыкланганнан соң 30 көннән дә соңга калмыйча, хезмәт күрсәтүче учреждение тарафыннан бетерелергә тиеш.

## V. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү.

5.1. Мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр тәртиптә шикаять бирергә хокуклы.

Мөрәҗәгать итүче шикаять белән шул исәптән түбәндәге очракларда мөрәҗәгать итә ала:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаны, ике һәм аннан да күбрәк муниципаль хезмәт күрсәтүне (алга таба – комплекслы запрос) теркәү вакытын бозу;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү срогын бозу. Әлеге очракта гариза язучы күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәрге (судтан тыш) шикаятьне әгәр дә гамәлләре (гамәл кылмаулары) турында сөйләшелә торган күпфункцияле үзәккә тиешле муниципаль хезмәт күрсәтү 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.3 өлештә билгеләнгән тәртиптә һәм тулы күләмдә йөкләнсә генә белдерә ала.

3) мөрәҗәгать итүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, Зәй муниципаль районы хокукый актларында каралмаган документларны яисә мәгълүматны сорау, гамәлләр кылуны таләп итү;

4) Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган очракта гариза язучыдан муниципаль хезмәт күрсәтү өчен документларны кабул итүдән баш тарту;

5) муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту, әгәр дә баш тару өчен нигезләр федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлары, әлеге административ регламент белән каралмаган булса. Әлеге очракта гариза язучы күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәрге (судтан тыш) шикаятьне әгәр дә гамәлләре (гамәл кылмаулары) турында сөйләшелә торган күпфункцияле үзәккә тиешле муниципаль хезмәтне күрсәтү 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.3 өлештә билгеләнгән тәртиптә һәм тулы күләмдә йөкләнгәндә генә белдерә ала;

6) муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, Зәй муниципаль районы хокукый актларында каралмаган түләүне таләп итү;

7) муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының, КФҮ, КФҮ хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешмаларның яки аларның хезмәткәрләренең муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе буларак «Электрон балалар бакчасы» автоматлаштырылган мәгълүмат системасына гариза керткәндә җибәрелгән опечаткаларны, хаталарны төзүтүдән баш тартулары. Әлеге очракта гариза язучы күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәрге (судтан тыш) шикаятьне әгәр дә

гамәлләре (гамәл кылмаулары) турында сөйләшелә торган күпфункцияле үзәккә тиешле муниципаль хезмәтне күрсәтү 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.3 өлештә билгеләнгән тәртиптә һәм тулы күләмдә йөкләнгәндә генә белдерә ала;

8) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү вакытын яки тәртибен бозу;

9) федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган очракта муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору. Әлеге очракта гариза язучы күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәрге (судтан тыш) шикаятьне әгәр дә гамәлләре (гамәл кылмаулары) турында сөйләшелә торган күпфункцияле үзәккә тиешле муниципаль хезмәтне күрсәтү 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.3 өлештә билгеләнгән тәртиптә һәм тулы күләмдә йөкләнгәндә генә белдерә ала;

10) муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән аларның булмавы һәм (яисә) аларның дөрес булмавы муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тартканда яисә муниципаль хезмәт күрсәтүләрдән баш тартканда күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматларны таләп итү, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган очраклардан тыш. Әлеге очракта гариза язучы күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәрге (судтан тыш) шикаятьне әгәр дә гамәлләре (гамәл кылмаулары) турында сөйләшелә торган күпфункцияле үзәккә тиешле муниципаль хезмәтне күрсәтү 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.3 өлештә билгеләнгән тәртиптә һәм тулы күләмдә йөкләнгәндә генә белдерә ала;

5.2. Мөрәҗәгать итүчеләр шикаятьне нигезләү һәм карау өчен кирәкле мәгълүмат һәм документлар алуга хокуклы.

5.3. Шикаять язмача рәвештә кәгазьдә яисә электрон рәвештә муниципаль хезмәтне күрсәтүче органга, күпфункцияле үзәккә йә күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючы дәүләт хакимиятенең тиешле органына (җирле үзидарә органына) һәм шулай ук 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешмаларга бирелә. Муниципаль хезмәтне күрсәтүче орган җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр югарырак органга (ул булган очракта) бирелә йә ул булмаган очракта муниципаль хезмәтне күрсәтүче органның турыдан-туры җитәкчесе тарафыннан карала. Күп функцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр шушы күпфункцияле үзәк җитәкчесенә бирелә. Күпфункцияле үзәкнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр күпфункцияле үзәкне оештыручыга яисә Татарстан Республикасының норматив хокукый акты белән вәкаләтле вазыйфаи затка тапшырыла. 210-ФЗ номерлы Федераль

законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешмалар хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр әлеге оешмалар җитәкчеләренә бирелә.

5.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының, муниципаль хезмәткәрнең, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр почта аша, КФҮ аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның рәсми сайтын, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталын яки дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләрнең төбәк порталын файдаланып юллана, шулай ук гариза тапшыручыны шәхсән кабул иткәндә бирелә алалар. КФҮ, КФҮ хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр почта аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен, КФҮ рәсми сайтын, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталын яки дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләрнең төбәк порталын файдаланып юллана, шулай ук гариза тапшыручыны шәхсән кабул иткәндә бирелә алалар. 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1.1 өлешендә каралган оешмаларның, шулай ук аларның хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр почта аша, «Интернет» мәгълүматтелекоммуникация челтәрен, әлеге оешмаларның рәсми сайтларын, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталын яки дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләрнең төбәк порталын файдаланып юллана, шулай ук гариза тапшыручыны шәхсән кабул иткәндә бирелә алалар.

5.5. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органга, күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючыга, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешмаларга яисә югарырак органга (ул булганда) кергән шикаять теркәлгәннән соң унбиш эш көне эчендә каралырга тиеш, ә муниципаль хезмәт күрсәтүче органга, күпфункцияле үзәккә, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешмаларга карата мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итү яисә җибәрелгән опечаткалар һәм хаталарны төзәтү яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозу буенча шикаять белдерелгән очракта - аны теркәгән көннән алып биш эш көне эчендә.

5.6. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, аның вазыйфаи затының исеме, яки муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, аның вазыйфаи затының, аның җитәкчесенең һәм (яки) 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ

номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган, карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган органнарының, аларның җитәкчеләре һәм (яки) хезмәткәрләренең исемнәре;

2) гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта), яшәү урыны турында мәгълүмат, шулай ук элемтә өчен телефон номеры, электрон почта адресы (булган очракта) һәм җавап бирүчегә җибәрелергә тиеш почта адресы;

3) муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи заты яисә муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1.1 өлешендә каралган оешмаларның, аларның хезмәткәрләренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи заты яисә муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1.1 өлешендә каралган оешмаларның, аларның хезмәткәрләренең гамәлләре (гамәл кылмаулары) белән алар нигезендә риза булмаган дәлилләре. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан гариза бирүченең дәлилләрен раслаучы документлар (булганда) яки аларның күчермәләре бирелергә мөмкин.

5.7. Мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яисә аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.8. Шикаятькә шикаятьтә бәян ителгән хәлләрне раслый торган документларның күчермәләре кушып бирелергә мөмкин. Мондый очракта шикаятьтә аңа теркәлә торган документлар исемлеге китерелә.

5.9. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча муниципаль хезмәт күрсәтүче орган түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны кире кагу, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән опечатка һәм хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары, Зәй муниципаль районы хокукый актлары белән каралмаган акчаларны кире кайтару рәвешендә дә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язма рәвештә һәм мөрәҗәгать итүченең теләге буенча электрон формада шикаятьне карау нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

5.10. Шикаять канәгатьләндерелергә тиешле дип танылган очракта гариза язучыга җибәрелә торган җавапта, муниципаль хезмәт күрсәткәндә

киткән җитешсезлекләрне тиз арада төзәтү максатыннан, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган, күпфункцияле үзәк яки 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган оешма тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук килеп туган уңайсызлыклар өчен гафу үтенеп, мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәтне алу максатларында алга таба башкарырга кирәк булган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә.

5.12. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта гариза язучыга җибәрелә торган җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.13. Шикаятьне карау барышында яисә карап тикшерү нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу составы билгеләре яки вазыйфаи затның җинаять эше билгеләре ачыкланганда, шикаятьне карау вәкаләтләре бирелгән хезмәткәр булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына юллый.

Административ регламентка
1 кушымта

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф оешмалары турында белешмәләр

| **Оешманың исеме** | **Җитәкченең фамилиясе, исеме, атасының исеме** | **Оешманың адресы/ сайты** | **Телефон** | **Оешманың эш режимы, җитәкченең кабул итү сәгатьләре** |
|---|---|---|---|---|
| «Гомумүстерү төрендәге «Аленка» балалар бакчасы» МБМБУ | Храмова Татьяна Валентиновна | 423520 ТР, Зәй ш., Баныкин ур., 9 й. zainskdou9@mail.ru | (885558) 71614 | 6.00 до 18.00 15.00 до 16.30 дүш.- җомга |
| «Гомумүстерү төрендәге «Алтынчәч» балалар бакчасы» МБМБУ | Ишмиева Ангелина Павловна | 423520 ТР, Зәй ш., Ленин ур., 34 «а» й. Leila_must@mail.ru | (885558) 75661 | 6.00 - 18.00 15.00 - 16.30 дүш.- җомга |
| «Каенкай» балалар бакчасы» МБМБУ | Степанова Венера Фаил кызы | 423520 ТР, Зәй ш., Клуб ур., 6 й. zainskdou14@mail.ru | (885558) 66190 | 6.00 - 18.00 15.00 - 16.30 дүш.- җомга |
| «Гомумүстерү төрендәге «Күкчәчәк» балалар бакчасы» МБМБУ | Иванова Светлана Николаевна | 423520 ТР, Зәй ш., Никифоров ур., 77 й. zainskdou12@mail.ru | (885558) 75484 | 6.00 - 18.00 15.00 - 16.30 дүш.- җомга |
| «Гомумүстерү төрендәге «Уймак кыз» балалар бакчасы» МБМБУ | Романова Анна Анатольевна | 423520 ТР, Зәй ш., Ленин ур., 18 «а» й. dyim1957@mail.ru | (885558) 75073 | 6.00 - 18.00 15.00 - 16.30 дүш.- җомга |
| «Бөртеккәй» балалар бакчасы» МБМБУ | Кузнецова Нина Николаевна | 423520 ТР, Зәй ш., Завод ур., 17«б» й. zainskdou6@mail.ru | (885558) 77414 | 6.00 - 18.00 15.00 - 16.30 дүш.-җомга |
| «Гомумүстерү төрендәге «Кыңгырау чәчәк» балалар бакчасы» МБМБУ | Вдовина Людмила Николаевна | 423520 ТР, Зәй ш., Чапаевур., 6 й. zainskdou7@mail.ru | (885558) 72386 | 6.00 - 18.00 15.00 - 16.30 дүш.- җомга |
| «Гомумүстерү төрендәге «Кызыл калфак» балалар бакчасы» МББМУ | Гришина Ирина Ивановна | 423520 ТР, Зәй ш., Рафиков ур., 4 «а» й. zainskdou@mail.ru | (885558) 31225 | 6.00 - 18.00 15.00 - 16.30 дүш.- җомга |
| «Гомумүстерү төрендәге «Урман әкияте» балалар бакчасы» МБМБУ | Габбасова Роза Сөббух кызы | 423520 ТР, Зәй ш., Җиңү пр., 1/01 й. zainskdou13@mail.ru | (885558) 33306 | 6.00 - 18.00 15.00 - 16.30 дүш.- җомга |
| «Компенсацияләүче төрдәге «Тату гаилә» балалар бакчасы» МББМУ | Петрякова Мария Юрьевна | 423520 ТР, Зәй ш., Ленин ур., 3 й. ZaiDrsem@mail.ru | (885558) 72637 | 6.00 - 18.00 15.00 - 16.30 дүш.-җомга |
| «Катнаш төрдәге Салават күпере» балалар бакчасы» МБМБУ | Отакулова Эльвира Мөнир кызы | 423520 ТР, Зәй ш., Җиңү пр., 14 «а» й. douraduga15@mail.ru | (885558) 33305 | 6.00 - 18.00 15.00 16.30 дүш.- җомга |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «Гомумүстерү төрендәге «Миләшкәй» балалар бакчасы» МБМБУ | Каштанова Елена Витальевна | 423520 ТР, Зәй ш., Пионер ур., 14 «б» й. vip.sabarova@mail.ru | (885558) 36115 | 6.00 - 18.00 15.00 - 16.30 дүш.- җомга |
| «Гомумүстерү төрендәге «Якты коңгыз» балалар бакчасы» МБМБУ | Гончарова Алина Фаяз кызы | 423520 ТР, Зәй ш., Энергетиклар ур., д. 13 «а» й. svetlyachok.zainsk@yandex.ru | (885558) 70959 | 6.00 - 18.00 15.00 - 16.30 дүш.- җомга |
| «Гомумүстерү төрендәге «Кояшкай» балалар бакчасы» МБМБУ | Исакова Альфира Габделбәр кызы | 423520 ТР, Зәй ш., Комсомол ур., 65 «а» й. zainskdou5@mail.ru | (885558) 70741 | 6.00 - 18.00 15.00 - 16.30 дүш.- җомга |
| «Гомумүстерү төрендәге «Теремкәй» балалар бакчасы» МБМБУ | Хөснетдинова Венера Ринат кызы | 423520 ТР, Зәй ш., Ленин ур., 6 «а» й. dou-teremok2013@yandex.ru | (885558) 70103 | 6.00 - 18.00 15.00 - 16.30 дүш.- җомга |
| «Катнаш төрдәге «Энҗе» балалар бакчасы» МББМУ | Мурзагова Венера Равил кызы | 423520 ТР, Зәй ш., Җиңү пр., 14 «б» й. zai.Enzhe@tatar.ru | (885558) 32698 | 6.00 - 18.00 15.00 - 16.30 дүш.- җомга |
| «Гомумүстерү төрендәге «Шатлык» балалар бакчасы» МБМБУ | Борһанова Рәзинә Хафиз кызы | 423520 ТР, Зәй ш., Жуков ур., 9 «а» й. shatlyk.zainsk@mail.ru | (885558) 28024 | 6.00 - 18.00 15.00 - 16.30 дүш.- җомга |
| «Гомумүстерү төрендәге «Тылсымлы әкият» балалар бакчасы» МБМБУ | Тимофеева Татьяна Геннадиевна | 423520 ТР, Зәй ш., Җиңү пр. 34 «а» й. zai.Volshebnaya@yandex.ru | (85558) 2-80-03 | 6.00 - 18.00 15.00 - 16.30 дүш.- җомга |
| «Күбәләк» Бигеш балалар бакчасы» МБМБУ | Зыятдинова Алсу Мәсгуть кызы | 423511 РТ, Зәй р-ны, Бигеш ав., Гагарин ур., 117«а» й. doubegish@mail.ru | (885558) 38038 | 7.00 - 16.00 15.00 - 16.00 дүш.- җомга |
| «Урман көе» Бохарай балалар бакчасы» МБМБУ | Миңлегулова Ләйлә Вәкил кызы | 423536 РТ, Зәй р-ны, Бохарай ав., Новая ур., 4 й. alsu.melodia@mail.ru | (885558) 40435 | 7.00 - 16.00 15.00 - 16.00 дүш.- җомга |
| «Родничок» Гулькин балалар бакчасы» МБМБУ | Григорьева Людмила Дмитриевна | 423507 РТ, Зәй р-ны, Гулькин ав., Үзәк ур., 23 й. gulkinods@mail.ru | (885558) 60807 | 7.00 - 16.00 15.00 - 16.00 дүш.- җомга |
| "Кояшкай" Кадер балалар бакчасы" МБМБУ | Исламова Рәйсә Сөләйман кызы | 423513 РТ, Зәй р-ны, Кадер ав., Яшьләр ур., 3 й. doukader@mail.ru | (885558) 63370 | 7.00 - 16.00 15.00 - 16.00 дүш.- җомга |
| «Ромашка» Сәвәләй балалар бакчасы» МБМБУ | Москова Елена Георгиевна | 423737 РТ, Зәй р-ны, Сәвәләй ав., Яшьләр ур., 1 й. dou.savaleevo@mail.ru | (885558) 62335 | 7.00 - 16.00 15.00 - 16.00 дүш.- җомга |
| «Аксар төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ | Хәсәншин Рафаил Мөнәвир улы | 423501, РТ, Зәй районы, Аксар ав., Мәктәп ур., 4 й. aksar37@mail.ru | 8(85558) 3-73-34 | 7.00 -16.00 15.00-16.00 дүш.- җомга |
| «Александр Бистәсе төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ | Чуприкова Эльза Таһир кызы | 423503, ТР, Зәй р-ны, Александр Бистәсе ав.,Үзәк урам, 72б й. alslobod77@mail.ru | 8(85558) 6-27-42 | 7.00-16.00 15.00-16.00 дүш.- җомга |
| «Югары Шепкә төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ | Закирова Венера Сәет кызы | 423518, ТР, Зәй р-ны, Югары Шепкә ав., Үзәк урам, 83 й. shipki21@mail.ru | 8(85558) 6-92-66 | 7.00 -16.00 15.00–16.00 дүш.- җомга |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| “Түбән Биш гомуми белем бирү мәктәбе” МБМУ | Иванов Сергей Владимирович | 423514, ТР, Зәй р-ны, Түбән Биш ав., Пролетар ур., 19 й. kaban603@mail.ru | 8(85558) 6-84-10 | 7.00-16.00 15.00-16.00 дүш.- җомга |
| «Поручик төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ | Хәсәншин Ринат Рәис улы | 423520, ТР, Зәй районы, Поручик ав., Чапаев ур., 25 й. sch_poruch@mail.ru | 8(85558) 3-70-96 | 7.00-16.00 15.00-16.00 дүш.- җомга |
| “Чыбыклы төп гомуми белем бирү мәктәбе” МБМУ | Мөхәммәтҗанова Җәмилә Фатих кызы | 423534, ТР, Зәй районы, Чыбыклы ав., Яшьләр ур., 229б й. chubuk3682@mail.ru | 8(85558) 3-68-57 | 7.00-16.00 15.00-16.00 дүш.- җомга |
| “Югары Налим төп гомуми белем бирү мәктәбе” МБМУ | Насыйров Илназ Илсур улы | 423533, ТР, Зәй р-ны, Югары Налим, Яшьләр ур., 1 й. vnalim36@mail.ru | 8(85558) 3-86-31 | 7.00-16.00 15.00-16.00 дүш.- җомга |
| “Якты Күл төп гомуми белем бирү мәктәбе” МБМУ | Кириллова Лидия Яковлевна | 423538, ТР, Зәй районы, Якты Күл ав., Ленин ур., 81 й. svetl68@mail.ru | 8(85558) 6-82-79 | 7.00- 16.00 15.00-16.00 дүш.- җомга |
| "Сарсаз-Баграж төп гомуми белем бирү мәктәбе" МБМУ | Мартемьянов Валентин Иванович | 423516, ТР, Зәй р-ны, Сарсаз-Баграж ав., Мәктәп ур., 4 й. sbag64@mail.ru | 8(85558) 6-44-27 | 7.00-16.00 15.00-16.00 дүш.- җомга |

Административ регламентка
2 кушымта

Шәхси мәгълүматларны автоматлаштырылган эшкәртүгә
РИЗАЛЫК

ГАРИЗА

Мин,__________________________________________________________,
*(Ф.И.О.)*

_____________________________________________________________,
*прописка буенча (теркәлү) адрес*

_____________________________________________________________,
*(шәхесне раслаучы документ төре, сериясе, номеры, кем тарафыннан бирелгән һәм бирелү датасы)*

Татарстан Республикасының мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына укырга керүче һәм чиратта торучы балаларның мәгълүматлар базасын формалаштыру максатыннан, шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык бирәм:

_____________________________________________________________,
*(Ф.И.О., ата-ананың берсенең (законлы вәкилнең) паспорты мәгълүматлары)*

_____________________________________________________________,
*(Ф.И.О., туу датасы, баланың туу турында таныклыгы мәгълүматлары)*

_____________________________________________________________,
*(факттагы яшәү адресы, баланың сәламәтлеге турында белешмәләр)*

____________________________________________________________,
*(мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенә ташламалы кучерүгә хокуклар булу)*

кәгазь һәм электрон формаларда автоматлаштырылган һәм автоматлаштырылмаган ысул белән шәхси мәгълүматларны җыюны гамәлгә ашыру, системалаштыру, туплау, саклау, төгәлләштерү (яңарту, үзгәртү), файдалану, тарату (шул исәптән тапшыру), зарарсызландыру, блоклау, юк итү.

Әлеге ризалыкның гамәлдә булу вакыты____________________________

Әлеге ризалык минем тарафтан язма рәвештә кире алынырга мөмкин. Әлеге ризалык кире алынган очракта, аның гамәлдә булу вакыты чыкканчы, мин шәхси мәгълүматларны эшкәртүне туктатуның мөмкин булган нәтиҗәләре турында кисәтелгән.

Дата _______________

Гариза бирүченең имзасы___________*(______________)(имзаның расшифровкасы)*